ГЛАВА
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.09.2023 с.Старое Дрожжаное № 40

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәренең коррупциягә каршы тору тәртибе стандартына үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгының 2012 елның 1 февралендәге 10 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәренең коррупциягә каршы тору тәртибе стандартына, **3.1 пунктындагы өченче абзацны** түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (тормыш иптәшенең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне тапшырмау, әгәр мондый белешмәләрне тапшыру мәҗбүри булса, тулы булмаган белешмәләр тапшыру, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, яки дөрес булмаган белешмәләр бирү муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.»

2. Әлеге карарны Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы А.Е. Ярухин